ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

реестр маршрутов

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 59** **28. 01.2019 ел**

**«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы территориясендә автомобиль транспорты белән пассажирлар һәм йөкләрне даими ташуның муниципаль маршрутлары Реестрын раслау турында»**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» №131-ФЗ Федераль законы, 2013 елның 13 июлендәге «Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән пассажирлар һәм йөкләр ташуны оештыру һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында № 220-ФЗ Федераль законы буенча, Спас муниципаль районы Уставына нигезләнеп, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы территориясендә автомобиль транспорты белән пассажирлар һәм йөкләрне даими ташуның муниципаль маршрутлары Реестрын әлеге Карарның Кушымтасы буенча расларга.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Спас муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге Карарны контрольдә тотуны Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Н.А. Казаковага йөкләргә.

Спас муниципаль районы башкарма
комитеты җитәкчесе: В.А. Осокин

# Даими ташу маршрутлары реестры

| Әлеге реестрда даими ташу маршрутының теркәү номеры | Даими ташу маршрутының тәртип саны | Даими ташу маршрутының исеме | Беренче тукталыш, беренче тукталыш урнашкан җирлек исеме | Соңгы тукталыш, соңгы тукталыш урнашкан җирлек исеме | Даими ташу маршруты буенча арадагы тукталышлар, арадагы тукталышлар урнашкан торак пунктларның исеме | Тукталышлар арасында даими ташу маршруты буенча транспорт чарасы йөри торган урамнарның, автомобиль юлларының исеме | Даими ташу маршрутының озынлыгы (әйләнеш/км) | Пассажирларны утырту һәм төшерү тәртибе | Транспорт чарасының төре | Транспорт чарасының классы | Транспорт чарасының экологик характеристикалары | Даими ташуларны башлау көне | Юридик затның исеме, урыны, шәхси эшмәкәрнең исем-фамилиясе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| № 1 | № 1 | Болгар шәһәре – Полянка авылы (Өчкүл, Үрнәк, Балымер авылларына керә) | Болгар, Хирург Шеронов урамы, 2 йорт | Полянка авылы, Үзәк урам, 14 йорт | Болгар,.Ленин урамы, 40 йорт, «Дорожник» кибете, Үрнәк авылы, Вахитов урамы, 26 йорт, Өчкүл авылы, Школьный урамы, 58 йорт | Болгар шәһәре, Хирург Шеронов урамы; Ленин урамы; Үрнәк авылы, Вахитов урамы; Өчкүл авылы, Школьный урамы; Полянка авылы, Үзәк урам | 32 км | Даими маршрут буенча юл хәрәкәте кагыйдәләре тарафыннан тыелмаган урында | Кимендә 15 кеше сыйдырышлы автобус | Д | Евро - 5 | 01.03.19 | |
| № 2 | № 2 | Болгар шәһәре – Ржавец авылы (Приволжск поселогына керә) | Болгар, Хирург Шеронов урамы, 2 йорт | Приволжск поселогы, Школьный урамы, 58 йорт | Болгар,.Ленин урамы, 40 йорт, «Дорожник» кибете, Ржавец авылы, Лесной урамы | Болгар шәһәре, Хирург Шеронов урамы; Ленин урамы; Приволжский поселогы, Школьный урамы; Ржавец авылы, Лесной урамы | 12 км | Даими маршрут буенча юл хәрәкәте кагыйдәләре тарафыннан тыелмаган урында | Кимендә 15 кеше сыйдырышлы автобус | Д | Евро - 5 | 01.03.19 | |
| № 3 | № 3 | Болгар шәһәре – Полянка авылы (Өчкүл, Балымер авылларына керә) | Болгар, Хирург Шеронов урамы, 2 йорт | Полянка авылы, Үзәк урам, 14 йорт | Болгар,.Ленин урамы, 40 йорт, «Дорожник» кибете, Өчкүл авылы, Школьный урамы, 58 Балымер авылы, Садовый урамы, 27 | Болгар шәһәре, Хирург Шеронов урамы; Ленин урамы; Өчкүл авылы, Школьный урамы, Балымер авылы, Садовый урамы; Полянка авылы, Үзәк урам | 25 км | Даими маршрут буенча юл хәрәкәте кагыйдәләре тарафыннан тыелмаган урында | Кимендә 15 кеше сыйдырышлы автобус | Д | Евро - 5 | 01.03.19 | |